**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2020 Балык Бистәсе штп. № 262пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен, җитәкче урынбасарларын билгеләп кую Регламенты турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 78 статьясындагы 3 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә туры китереп КАРАР БИРӘМ:

1."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен, җитәкче урынбасарларын билгеләп кую Регламентын расларга (алга таба-Регламент, Башкарма комитет).

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1) Башкарма комитет җитәкчесе Регламент нигезендә муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен һәм башлыкларын вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү, алар белән хезмәт шартнамәләрен төзү һәм туктату турында карарлар кабул итә;

2.2 Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары булган муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре, юридик зат статусына ия муниципаль казна учреждениеләре башлыклары, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре, Регламент нигезендә, муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларын, муниципаль казна учреждениеләре башлыклары урынбасарларын, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү турында карарлар кабул итәләр, алар белән хезмәт шартнамәләрен төзиләр һәм туктаталар.

3.Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карар нигезендә муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен, муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләрен, Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары булган муниципаль казна учреждениеләре башлыкларын билгеләүне тәэмин итәргә.

4. Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары булган, юридик зат статусына ия муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренә, муниципаль казна учреждениеләре башлыкларына:

4.1)әлеге карар нигезендә муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларын, муниципаль казна учреждениеләре башлыклары урынбасарларын, ведомство карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләрен билгеләп куюны тәэмин итәргә;

4.2) 2021 елның 1 февраленә кадәр Башкарма комитетның оештыру бүлеге белән берлектә ведомство карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре, муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарлары белән элек төзелгән хезмәт килешүләрен әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Исланов Р. Л.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 декабрендәге 262пи номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен, җитәкче урынбасарларын билгеләп кую Регламенты**

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен (шул исәптән башлыкларны) вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба- Башкарма комитет җитәкчесе) тарафыннан, әлеге учреждениенең эшчәнлегенә кураторлык итүче башкарма комитет җитәкчесе урынбасары тәкъдиме һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (алга таба-Аппарат җитәкчесе) белән килешенеп гамәлгә ашырыла (кушымта).

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларны вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү муниципаль хезмәт турындагы закон таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.Башкарма комитет җитәкчесе һәм муниципаль казна учреждениесе, муниципаль унитар предприятие җитәкчесе арасында билгеләнгән тәртиптә расланган типик формалар нигезендә хезмәт килешүе төзелә.

3.Муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларын вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү, Башкарма комитетның 2020 елның 23 мартындагы 08р номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль казна учреждениеләренә караган муниципаль бюджет учреждениеләре Исемлеген исәпкә алып, әлеге муниципаль казна, бюджет учреждениесе эшчәнлегенә кураторлык итүче һәм контрольдә тотучы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары белән килешеп, муниципаль казна учреждениесе, муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.Муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе һәм муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе арасында билгесез срокка хезмәт килешүе төзелә.

5.Муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе һәм муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары арасында билгесез срокка хезмәт килешүе төзелә.

6.Муниципаль унитар предприятие җитәкчеләре урынбасарларын вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү муниципаль унитар предприятие җитәкчесе тарафыннан әлеге муниципаль унитар предприятиенең эшчәнлегенә

кураторлык итүче һәм контрольдә тотучы Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары белән килешенеп гамәлгә ашырыла.

7.Муниципаль унитар предприятие җитәкчесе һәм муниципаль унитар предприятие җитәкчесе урынбасары арасында билгесез срокка хезмәт килешүе төзелә.

8.Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре белән хезмәт килешүен рәсмиләштерү, төзү һәм килештерү белән бәйле барлык оештыру-кадрлар чаралары Башкарма комитетның оештыру бүлеге (кадрлар хезмәте) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9.Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль бюджет җитәкчеләре урынбасарлары белән хезмәт килешүе төзү һәм килештерү белән бәйле барлык оештыру-кадрлар чаралары тиешле муниципаль казна учреждениесе, муниципаль унитар предприятие кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль унитар предприятиеләр (муниципаль учреждениеләр) белгечләрен билгеләү тиешле муниципаль унитар предприятие (муниципаль учреждение) җитәкчесе тарафыннан башкарыла. Муниципаль унитар предприятие (муниципаль учреждение) җитәкчесе һәм муниципаль унитар предприятие (муниципаль учреждение) белгече арасында хезмәт килешүе төзелә.

10. Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең хезмәт кенәгәләре, шәхси эшләре Башкарма комитетның оештыру бүлегендә (кадрлар хезмәтендә) саклана.

11. Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларының хезмәт кенәгәләре, шәхси эшләре тиешле муниципаль казна учреждениесенең, муниципаль унитар предприятиенең яки муниципаль бюджет учреждениесенең кадрлар хезмәтендә саклана.

12.Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең чираттагы ялларын, командировкаларын рәсмиләштерү Башкарма комитетның оештыру бүлеге (кадрлар хезмәте) тарафыннан башкарыла.

13.Муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләрнең, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарларының чираттагы ялларын, командировкаларын рәсмиләштерү тиешле муниципаль казна учреждениесенең, муниципаль унитар предприятиенең яисә муниципаль бюджет учреждениесенең кадрлар хезмәте тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләрен, җитәкче урынбасарларын билгеләп кую Регламентына кушымта

ТӘКЪДИМНАМӘ

Балык Бистәсе муниципаль районы
Советының аппарат җитәкчесе белән
КИЛЕШТЕРЕЛГӘН
______________________ _________
"__" ________ 20_ ел.

Хөрмәтле __________________________!

Муниципаль казна учреждениесе (муниципаль унитар предприятие) башлыгы (җитәкчесе, директоры) вазыйфасына билгеләп кую өчен тәкъдим итәм
_______________________________________________________________________________
( учреждения, (предприятие) исеме)
_______________________________________________________________________________
( тәкъдим ителүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Кушымта:
1. Гариза.
2. Анкета яки шәхси кәгазь (паспорт мәгълүматлары, йорт адресы, йорт һәм эш телефоннары күрсәтелгән һәм фоторәсемнәр теркәлгән).

Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары: ___________(Ф.И.А.и)